РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

12.12.2023 ел №218

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 18 ноябрендәге № 76 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге №414-ФЗ, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге № 99-ТРЗ Федераль законнар, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 2021 елның 18 ноябрендәге № 76 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына (район Советының 2022 елның 31 мартындагы №98, 2023 елның 28 мартындагы №173, 2023 елның 24 июлендәге №190 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.13 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «4.13 класс чины бирү көне дип класс чины бирү турында карар кабул ителгән көн санала».

1.2. Нигезләмәнең 4.21 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «4.21 Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында карар, Нигезләмәнең 4.15 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чинын бирү турында барлык кирәкле документлар белән органга яки җирле үзидарәнең класс чинын бирергә

вәкаләтле вазыйфаи затына тапшыру турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов